| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛЕВАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЛЕВАШЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.06.2020 Левашево ав. № 15

**Гражданнар милкенә торак урыннар тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Ана (гаилә) капиталы чаралары белән бәйле мәсьәләләр буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 01 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә туры китерү максатларында

**карар кылам:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Левашево авыл җирлеге башкарма комитетының 2014 елның 18 февралендәге 7 номерлы карары белән расланган гражданнар милкенә торак урыннары тапшырганда документларны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертергә:

- «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасы эчтәлегенә 2.5 нче юлларны үз көчен югалткан дип санарга;
- 5.1 пунктының 9,10 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) әгәр туктатып тору нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәк хезмәткәре тарафыннан күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү, карар һәм гамәлләр (гамәл кылмауларына) дәгъва белдерелә торган күпфункцияле үзәккә «Дәүләт һәм

муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

10) Мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә документлар яисә мәгълүмат бирелгәндә, аларның булмавы һәм (яисә) дөреслеге муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баштa баш тартканда йә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 маддәсендәге 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартканда күрсәтелмәгән. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәк хезмәткәре тарафыннан күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) дәгъва белдерелә торган күпфункцияле үзәккә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүләр буенча йөкләнгән очракта мөмкин.

- 5.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазь чыганакта, электрон рәвештә муниципаль хезмәтне күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә йә күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы булып торучы дәүләт хакимиятенең тиешле органына (җирле үзидарә органына) һәм шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1 бүлегендә каралган вәкаләтле оешмаларга бирелә».

Муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр югарырак органга (ул булган очракта) бирелә йә ул булмаган очракта турыдан-туры муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала.

Күп функцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр шушы күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә.

Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты белән вәкаләтле күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга яисә вазыйфаи затка тапшырыла.

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1_1 өлешендә каралган оешмалар хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр әлеге оешмалар җитәкчеләренә тапшырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтыннан (http://www.alekseevskiy.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан

(http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталыннан (http://wwww.gosuslugi/) файдаланып, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул иткәндә кабул итәргә мөмкин.

Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) дәгъва, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, почта аша, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр Бердәм порталының (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталының (http://www.gosuslugi.ru/) рәсми сайты, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итәргә мөмкин.

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1_1 өлешендә каралган оешмалар, шулай ук аларның хезмәткәрләре, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен кулланып, почта аша, әлеге оешмаларның рәсми сайтларын, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Бердәм порталын (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталын (http://www.gosuslugi.ru/) кулланып, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итәргә мөмкин.

- 5.7 пунктындагы 5 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шикаятьне канәгатьләнергә тиешле дип таныган очракта, мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк йә вәкаләтле оешма тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган хокук бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр, һәм мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт алу максатларында башкарырга тиешле алга таба гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталындагы җирлек сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Левашево авыл җирлеге Советы бинасында махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районының**
**Левашево авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **С.А.Демидова**